**Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы № 85 "05"апрель 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 июнендәге 100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында (11.10.2018 № 112, 18.03.2019 №129, 01.08.2019 № 142 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 июнендәге 100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында (11.10.2018 № 112, 18.03.2019 №129, 01.08.2019 № 142 карарлар редакциясендә) «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Й.Әхмәтшин